# ЗАКОН
## Республики Татарстан

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>1 статья.</u> Аннан соң кертелгән үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән "Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советының Җыелма басмасы, 1992 ел, 3 нче сан, 1994 ел, 3 нче сан, Татарстан Дәүләт Советының Җыелма басмасы, 1995 ел, 7-8 нче саннар, 1995 ел, 9 нчы сан) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

5 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарә органнары һәм бүлекчәләре";

6 статьяның 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарә органнары һәм бүлекчәләре";

7 статьяның 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарә органнары һәм бүлекчәләре".

<u>2 статья.</u> Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 11 июле
N 696